ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автотранспорт чараларын җитештерүче оешмалар өчен махсус инвестиция контрактында каралган инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны реализацияләүдән салым исәп-хисабы буенча беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы, ләкин 2025 елдан (бу елны да кертеп) соңрак түгел, Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 0 процент күләмендә билгеләнә.»;

2) 4 өлештә «алдагы ун салым чоры дәвамында» сүзләрен төшереп калдырырга, «ләкин махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң түгел» сүзләрен «махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганчы, ләкин 2023 елның 1 гыйнварыннан соңрак түгел» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач, әмма оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан да иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 19-ТРЗ